ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.12.2019**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2750**

Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт,чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия турында

Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, рәсми булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадта тискәре тенденцияләрне җиңү буенча алга таба эш алып баруны тәэмин итү, шулай ук Зеленодольск муниципаль районына чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү ихтыяҗын билгеләү эшен координацияләү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 12 сентябрендәге 800 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәтне, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалтуын танырга:

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 мартындагы 693 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 1926 елның 22 июлендәге 1926 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2016 елның 06 маендагы 1172 номерлы үзгәрешләр белән);

2017 елның 2 ноябрендәге 2752 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил

хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»
2018 елның 14 августындагы 1669 номерлы «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

3. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - М.З. Усмановка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 16 декабрендәге 2750
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе** | |
| Усманов Марат Зәкәри улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| **Комиссия рәисе урынбасары** | |
| Гататдинова Светлана Владимировна | «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |
| **Комиссия секретаре** | |
| Калистратова Ольга Николаевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге баш белгече |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Нурмухаметов Амир Җамил улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| Афанасьева Раиса Валиевна | Җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Лулаков Денис Владиславович | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Стерякова Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализ бүлеге башлыгы |
| Шакиров Марат Госман улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы |
| Анисимов Денис Сергеевич | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Алексахина<br>Анна<br>Юрьевна | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесе |
| Дёгтева<br>Ольга<br>Павловна | «Зеленодольск муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» МУ җитәкчесе |
| Пименова<br>Наталья<br>Николаевна | «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» МКУ җитәкчесе |
| Антонова<br>Мария<br>Михайловна | «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» ЗМР АУ җитәкчесе |
| Герт<br>Маргарита<br>Владимировна | Зеленодольск шәһәрендә дәүләт статистикасы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Григорьев<br>Анатолий<br>Александрович | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы Зеленодольск шәһәрендәге бүлегенең (килешү буенча) |
| Зиганшин<br>Таһир<br>Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Афлетонова<br>Альбина<br>Марат кызы | ТР буенча ФССП идарәсенең Зеленодольск районы суд приставлары бүлеге башлыгы - өлкән суд приставы (килешү буенча) |
| Билалиева<br>Лариса<br>Витальевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабурский<br>Алексей<br>Вячеславович | РФ Пенсия фондының Зеленодольск шәһәре, Зеленодольск һәм Югары Ослан районнары буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Трифонов<br>Анатолий<br>Александрович | Зеленодольск шәһәр прокуроры, юстициянең өлкән киңәшчесе (килешү буенча) |
| Евграфов | Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының |

| | |
|---|---|
| Сергей Алёшевич | Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча бүлегенең икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору бүлеге башлыгы(килештерү буенча) |
| Грошев Игорь Иванович | Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Тихонова Марина Владимировна | Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешә йөртүне һәм сыйфатына дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясенең Зеленодольск территориаль органы башлыгы (килешү буенча) |
| Фахритдинова Ильвира Рафик кызы | Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Зеленодольск бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Светлов Роман Викторович | Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча бүлеге башлыгы урынбасары - полиция башлыгы (килешү буенча) |
| Нигъмәтҗанов Ринат Галимҗан улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча бүлегенең наркоконтроль бүлеге башлыгы - полиция майоры (килешү буенча) |
| Донченко Эдуард Николаевич | Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча региональ бүлеге - Дәүләт учреждениесенең 14 нче филиалы директоры (килешү буенча) |
| Антипов Константин Сергеевич | Зеленодольск муниципаль районының Профсоюзлар оешмалары координация Советы рәисе (килешү буенча) |
| Гордеева Лариса Викторовна | Зеленодольск муниципаль районы Советының социаль-икътисадый үсеш, бюджет - финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшмәкәрлекне үстерү буенча даими комиссиясе рәисе (килешү буенча)) |
| Тутаева Наталья Евгеньевна | Зеленодольск муниципаль районында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 16 декабрендәге
2750 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1.Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү,рәсми булмаган хезмәт базарын кыскарту һәм икътисадта тискәре тенденцияләрне җиңү, шулай ук виза нигезендә Россия Федерациясенә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә булган ихтыяҗны билгеләү эшендә катнашу максатларында оештырылган.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, «Чит ил гражданнарының Россия Федерациясендә хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү, чит ил гражданнарына хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясенә керү өчен чакырулар бирү квотасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясенә эшкә рөхсәтләр нигезендә килүче чит ил гражданнарына бирү квоталарын раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 12 сентябрендәге 800 номерлы карарына, Россия Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

социаль-икътисадый өлкәдә тенденцияләргә, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителә торган карарларның халыкның яшәү сыйфатына йогынтысына мониторинг ясау;

хезмәт базарын тотрыклыландыру, керемнәрне легальләштерү, күләгәдәге икътисад һәм рәсми булмаган хезмәт базары йогынтысы аркасында барлыкка килгән Татарстан Республикасы икътисадындагы тискәре тенденцияләрне бетерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;

эш бирүчеләрнең минималь куллану бюджеты күләме зурлыгыннан ким булмаган күләмдә хезмәт хакын һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен үз вакытында түләнүен тәэмин итүгә, халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның чынбарлыктагы керемнәрен арттыруга, шулай ук пенсия яшендәге затларга карата эш бирүчеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен координацияләүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү;

рәсми булмаган икътисад һәм хезмәт базары тенденцияләрен һәм масштабларын ачыклау максатында социологик тикшеренүләр үткәрү турында тәкъдимнәр әзерләү;

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан, оештыру-хокукый рәвеше һәм милек рәвеше нинди булуга карамастан, хуҗалык итүче субъектларның (алга таба - хуҗалык итүче субъектлар) чыгымнар структурасына үзгәрешләрне анализлау, шушы базада өстәмә кыйммәтне арттыру, хезмәт хакын күтәрү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар тәкъдимнәре буенча милекчеләр тарафыннан үз вакытында идарә итү карарларын кабул итү өчен тәкъдимнәр эшләү һәм хуҗалык итүче субъектларның түли алмаучанлыгын белә торып барлыкка китерелүен яисә арттырылуын кисәтүгә юнәлдерелгән эш-гамәлләрне тормышка ашыру максатларында кризис хәлендәге хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлегенә мониторинг;

кызыксынган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары инициативасы буенча Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан аерым хуҗалык итүче субъектларының банкротлыкка чыгуын кисәтү буенча чаралар күрү турындагы тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук күрсәтелгән хуҗалык итүче субъектларына карата тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны бөлгенлек (банкротлык) процедураларын башлап җибәрүгә вәкаләтле органнар каравына кертү;

Зеленодольск муниципаль районында социаль ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын, адреслылыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар тәкъдимнәре буенча милекчеләр тарафыннан үз вакытында идарә итү карарларын кабул итү өчен тәкъдимнәр эшләү һәм хуҗалык итүче субъектларның түли алмаучанлыгын белә торып барлыкка китерелүен яисә арттырылуын кисәтүгә юнәлдерелгән эш-гамәлләрне тормышка ашыру максатларында кризис хәлендәге хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлегенә мониторинг;

кызыксынган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары инициативасы буенча Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан аерым хуҗалык итүче субъектларының банкротлыкка чыгуын кисәтү буенча чаралар күрү турындагы тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук күрсәтелгән хуҗалык итүче субъектларына карата тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны бөлгенлек (банкротлык) процедураларын башлап җибәрүгә вәкаләтле органнар каравына кертү;

эш бирүчеләрнең, эш (хезмәт күрсәтүләргә) заказ бирүчеләрнең (алга таба - эш бирүчеләрнең) Россия Федерациясенә виза нигезендә килә торган чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә, вакантлы һәм булдырыла торган эш урыннарын биләү яки Зеленодольск муниципаль районында эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен (алга таба-эш бирүчеләр) турындагы гаризаларын карау;

законнар нигезендә башка функцияләрне гамәлгә ашыру.

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларына Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм башка вазыйфаи затларын, шулай ук хуҗалык

итүче субъектларның эш төркемнәре (советлар, комиссияләр) җитәкчеләрен чакырырга;

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, , шулай ук хуҗалык итүче субъектларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрергә;

Комиссия тарафыннан ачыкланган хокук бозулар турында Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына ,федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, законнар нигезендә чаралар күрү максатларында мәгълүмат җибәрергә;

Комиссия эшендә ярдәм күрсәтү өчен хокук саклау органнарын, шулай ук Комиссия һәм күрсәтелгән органнар арасында төзелә торган тиешле килешүләр нигезендә дәүләт күзәтчелеген һәм контролен гамәлгә ашыручы башка органнарны чакырырга, аларга Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр бирергә;

кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, хуҗалык итүче субъектлар белгечләре, шулай ук Комиссия компетенциясенә караган карарлар һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу өчен чит ил белгечләрен чакырырга;

Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәрен төзергә.

5. Комиссия Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасарлары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә.

6.Комиссия составына социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы территориаль комиссия, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләре керә. Комиссия составына башка затлар да кертелергә мөмкин. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен җәмәгать башлангычларында алыштыру хокукыннан башка гамәлгә ашыралар.

7.Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

8.Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышы, әгәр утырышта әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, гамәли хокуклы дип санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары, аның утырышында катнашкан әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Утырыш беркетмәсенә Комиссия рәисе кул куя.

9. Комиссия Рәисе:

аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;

Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә.

10. Комиссия рәисе урынбасары:

комиссия рәисе булмаганда ,аның вазыйфаларын башкара; комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти.

11. Комиссия секретаре:

Комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара.

12. Комиссиянең үз атамасы күрсәтелгән бланкы була.

13. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.